**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5657**
**01.11.2019**

Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге»
муниципаль автономияле учреждениесе
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсе 1 бүлегенең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41, 53, 55 маддәләре, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 санлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләренә тарифлар билгеләү хакында карарлар кабул итү тәртибе турындагы нигезнамәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. 2017 елның 24 мартында «Челнинские известия» газетасының 20 нче санында басылып чыккан Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2017 елның 17 мартындагы 1396 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 1 ноябрендәге
5657 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Нур» яшьләр үзәге»
муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум. |
|---|---|---|---|
| 1. | Иҗатны үстерү буенча мастер-класс | 1 сәгать | 100,00 |
| 2. | Арт-Терапия | кеше/2 сәгать | 900,00 |
| 3. | «Картина» мастер-классы | кеше/2 сәгать | 1 700,00 |
| 4. | Шөгыльләнә башлаучылар өчен матурлык дәресләре | кеше/1 сәгать | 250,00 |
| 5. | Матурлык дәресләре (киңәйтелгән курс) | кеше/1 сәгать | 350,00 |
| 6. | Макияж курсы | кеше/4 сәгать | 4 000,00 |
| 7. | Аппаратура арендалау | 1 сәгать | 350,00 |
| 8. | Компьютерны Интернетка керү мөмкинлегеннән тыш арендалау | 1 сәгать | 10,00 |
| 9. | Компьютерны Интернетка керү мөмкинлегеннән файдаланып арендалау | 1 сәгать | 40,00 |
| 10. | Текстлы документларның, графика, сәнгать документларының күчермәләрен ясау | 1 бит | 4,00 |
| 11. | Оператор аша гади текст җыю һәм редакцияләү | 1 бит | 8,00 |
| 12. | Оператор аша графика, сәнгать документлары җыю һәм редакцияләү | 1 бит | 13,00 |
| 13. | Принтерда текстлы документлар бастыру | 1 бит | 4,00 |
| 14. | Принтерда графика, сәнгать документлары бастыру | 1 бит | 7,00 |
| 15. | Семинар (чара) оештыру | 1 семинар (чара) | 3 500,00 |
| 16. | Бәйрәм программасы үткәрү | кеше/2 сәгать | 500,00 |
| | | кеше/1,5 сәгать | 400,00 |
| 17. | Балалар иртәлеге үткәрү | кеше/2 сәгать | 350,00 |
| 18. | Корпоратив кичә үткәрү | кеше/6 сәгать | 500,00 |
| 19. | Күңел ачу программасы үткәрү | кеше/1,5 сәгать | 120,00 |
| 20. | Интерактив программа үткәрү | кеше/1 сәгать | 200,00 |
| 21. | Тематик чара оештыру һәм үткәрү | 2 сәгать | 5 000,00 |
| 22. | Корпоратив уен оештыру һәм үткәрү | 1 уен | 5 000,00 |
| 23. | Күргәзмәләр оештыру | 1 хезмәт күрсәтү | 3 500 ,00 |
| 24. | Алып баручы хезмәте | 1 сәгать | 2 000,00 |
| 25. | Аниматор хезмәте | 1 сәгать | 130,00 |
| 26. | Сценарий язу | 1 данә | 3 500,00 |
| 27. | Костюм прокаты | 1 тәүлек | 500,00 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева